Республика Татарстан
СОВЕТ ВЕРХНЕСИМЕТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422068, Республика Татарстан,
с.Верхний Симет, ул. Советская, 32
тел. 45-0-19

Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ СИМЕТ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422068 Татарстан Республикасы,
Югары Симет авылы , Совет урамы, 32 йорт
тел. 45-0-19

e-mail: Bsim.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
19.12.2023 г.

КАРАР
№ 27

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет җирлеге Советының 08.11.2021 ел, №22 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 12.10.2023 елның 01-54/7098 номерлы тәкъдим ителгән куркыныч индикаторлары турындагы хатын караганнан соң, Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге Советы Карар итә:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге Советының «Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 08.11.2021 ел, №22 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә (алга таба – положение тексты буенча) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче кушымтаны яна редакциядә Кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/simet адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Югары Симет авыл җирлеге башлыгы И.Р.Әхмәдуллин

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары авыл җирлеге Советының 19.12.2023 елгы 27 нче номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Югары Симет авыл
җирлеге территориясендә муниципаль
торак контроле турында 2нче Нигезләмә

**Муниципаль контроль үткәргәндә контроль чаралар үткәрү өчен нигез буларак кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары**

1. Муниципаль торак фондының торак биналары булган күпфатирлы йортта, көн тәртибендәге шундый ук мәсьәләләр буенча карарлар булган, милекчеләрнең гомуми җыелышының ике һәм аннан да күбрәк беркетмәсен өч ай рәттән муниципаль торак контроле органына кертү.

2. Бердәм диспетчерлык хезмәте мәгълүматларына караганда, контрольдә тотылган зат идарәсендә күп фатирлы йортта гомуми милектәге җитешсезлекләрне бетерү буенча эшләр башкару өчен атнага биштән артык ремонт бригадасы чакырылган очракта.

3. Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү документларында күпфатирлы йорт милекчеләренең гомуми мөлкәтен файдаланганда һәм тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен түләү күләмен алдагы шундый ук исәп-хисап чоры белән чагыштырганда 50% тан артык арттыру турында белешмәләрне ачыклау.